Татар әдәбиятының тарихы мең елдан артып китә. Аның асылын тәшкил иткән мәдәни мирасыбызда халыкның яшәү рәвеше, традицияләре, теләк-омтылышлары чагылыш табкан һәм алар гасырлар дәвамында рухи таяныч, гыйбрәтле үрнәк, өмет-ышаныч чыганагы булып торган. Борынгы чорлардан алып бүгенгегә кадәр халыкның фикердәше, юл күрсәтүчесе, юлдашы булган әдәби әсәрләрдән башка үткән тарихыбызны да, бүгенгене һәм киләчәгебезне дә дөрес һәм тулы аңлап, билгеләп булмас иде. Әлеге рухи байлыкны киң катлам укучыларга җиткерүдә китапның, язма сүзнең роле гаять зур. Ә инде XX гасыр башыннан әлеге бурычның зур өлешен газета һәм журналлар үти башлый. Соңгылары арасында «Казан утлары» журналы үзгә урын алып тора. Халык шагыйре Р.Фәйзуллин билгеләп үткәнчә, «Казан утлары» – матбугатыбыз тарихында уникаль басма: афәтле репрессия, дәһшәтле сугыш елларында илдә күп газета-журналлар ябылып, тукталып калганда да, ул, язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклап, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды» [1: 7]. Журналда төрле елларда баш мөхәррир булып танылган әдипләр, журналистлар эшли: Г.Мансуров, Г.Ибраһимов, Г.Бәширов, Г.Иделле, Р.Ильяс, Т.Имаметдинов, Г.Кашапов, К.Нәҗми, А.Шамов, А.Гомәр, Г.Мөхәммәтшин, Р.Мостафин, З.Нури, Г.Ахунов, Р.Харис, Р.Фәйзуллин. Бүген журналны шагыйрь Илфак Ибраһимов җитәкли. Чын мәгънәсендә халык журналы, киң катлам әдәбият сөючеләр – язучылар, зыялылар, укытучылар, студентлар, игенчеләр һәм хезмәткәрләр журналы булып кала алган «Казан утлары» үткән юл, халык язмышына бәйле рәвештә, гаять үзенчәлекле һәм гыйбрәтле.

«Казан утлары» үзенең рәсми тарихын «Безнең юл» исеме белән 1922 елда башлап җибәрә. Бу урында шуны да билгеләп үтү кирәк: XX гасыр башында татар телендә әдәби һәм иҗтимагый эчтәлекле «Әлгасрелҗәдид», «Шура», «Аң» кебек журналлар чыга. Алар арасында «Шура» журналы үзенең эчтәлеге, иҗтимагый-сәяси, әдәби-мәдәни яшәешне иңләп алуы, катнашучы авторлар яшәгән төбәкләр географиясе, иң мөһиме, язмаларның сыйфаты, җитдилеге, актуаль мәсьәләләрне кыю күтәрүе белән аерылып тора. Шуңа да «Безнең юл» ның рухи нигезе хаклы рәвештә «Шура» га барып тоташа [2: 11].

Яңа журнал беренче адымнарында ук әдәбиятны үстерүне, аның заман таләпләренә җавап бирүен күздә тота. Бу уңайдан журнал идарәсенең әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә[1] атап беренче санда басылган мөрәҗәгате игътибарга лаек: «Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, “Безнең юл” журналын чыгара башладык. “Безнең юл” ның чыгуы Татар җөмһүриятенең мәркәзендә – Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без, эчке, Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында яшәүче

[1] Мөхибләренә – сөючеләргә. Алга таба аңлатма сүзләр җәя эчендә курсив белән бирелә.

әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде.

Кулъязмалар өчен акча түләнә. Даими абүнә җыючылар, даими язучылар белән аерым мөгаһәдәләр (*килешүләр*) ясала. Эшче-крестьян гаммәсенең (*массасының*) азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булышсыннар иде» [3: 13].

Әдәби басма чыгару мәсьәләсенең куелышы, бу юлда очраган кыенлыклар, аны оештыруда актив катнашучылар турында 1923 елның 7 санына кадәр журналның җаваплы мөхәррире булып эшләгән Гасыйм Мансуров «Безнең юл» турында» дигән мәкаләсендә болай дип яза: «Ул вакыттагы шартлар эчендә (ачлык, хуҗалык эшләренең таркаулыгы. – *Г.М.)* татар вакытлы матбугатының хәле бик авыр иде. Ләкин без, шул авыр хәлләргә карамастан, татар вакытлы матбугатын яхшыртырга, көчәйтергә тотындык. 22 нче елның башы белән партиялеләрдән мин, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Гаяз Максуд, партиясезләрдән Садрый Җәләл, Газиз Гобәйдуллин, фикер алышканнан соң, “Безнең юл” журналы чыгарырга карар бирдек. Өлкә комитетыннан уздырып, Совнаркомнан акчалар алганчы, беренче номер басылганчы, байтак вакыт үтеп китте. Мартта чыгарырга тиеш булган журнал майда гына чыкты. <…> Революция шикелле кайнаган бер заманда татар телен бозылудан саклау да бик зур файда китерде.

“Безнең юл” ның йомшак якларына килсәк, мин түбәндәге нәрсәләрне күрсәтер идем:

1) “Безнең юл”, әдәби журнал була алганчы, бик төрле типта чыккалады;

2) Әле хәзергә чаклы тәнкыйть бүлеге үзенә тиешле урынны ала алганы юк. “Безнең юл” га тәнкыйть бүлеген көчәйтергә, матур, тулы каләмле бик үткен тәнкыйть кирәк.

Теләкләрем:

1) “Безнең юл” Татарстан өчен генә түгел, Русиядә яшәүче бөтен татарларга каратып чыгарылырга тиеш…» [4: 15].

«Безнең юл» журналы татар әдәбиятын һәм сәнгатен әйдәп баручы үзәккә әверелә. Октябрь инкыйлабыннан соң әдәби иҗатка килгән яшь авторлардан Һ.Такташ, Г.Кутуй, К.Нәҗми, М.Җәлил, бераз соңрак Х.Туфан, Ш.Маннур, Ф.Кәрим һ.б. беренче адымнарын әлеге басмада башлый. Журнал әдәби тәнкыйтьне үстерүгә һәм баетуга да зур өлеш кертә. Г.Рәхим, Г.Гали. Г.Нигъмәти, Г.Толымбай кебек тәнкыйтьчеләр үсеп чыга; яңа әдәбият, аның эчтәлеге, традицияләр һәм яңачалык буенча җитди бәхәсләр оештырыла. Әлеге чор үзенчәлеге турында язучы, әдәбият галиме Мөхәммәт Галинең фикере игътибарга лаек: «Хәзерге вакытта “Безнең юл”– әдәбият сөючеләр өчен бөтен татар дөньясында бердәнбер нәфис әдәби журнал. Бер яктан, ул хәзерге яшьләребезнең әдәби тойгыларын тәрбияләп, аларның гыйльми, иҗтимагый белемнәрен күтәрүдә булышлык итеп килсә, икенче яктан, хәзерге яшь язучыларыбыз шуның аркылы үзләренең әдәби каләмнәрен очлыйлар һәм шомарталар. <…> Гомумән, тип ягыннан алганда, “Безнең юл”ның хәзерге бара торган юлы ярый торган. Тик шуны эчке һәм тышкы яктан ыспайларга, бизәкләргә һәм шомартырга гына кирәк. Иң башлап ничектер менә шуның тышкы кыяфәте һәм күренеше белән ниндидер бер учреждение тарафыннан чыгарылып килә торган бюллетеньне һәм отчетны хәтерләтә» [5: 20].

Журнал, тормышның башка якларын да игътибар үзәгендә тотып, аеруча җитди мәсьәләләргә караш-мөнәсәбәтен укучыларга җиткерү максатын куя. Мисал өчен, 1921-24 елларда ТАССРның Үзәк башкарма комитеты рәисе булган Рәүф Сабировның беренче санда ук басылган «Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык» дигән мәкаләсендә 1921 елгы ачлыкның тарихи сәбәпләре турында уйланулары бирелә. Язма бүгенге көн укучысы өчен дә гыйбрәтле: «Гомумән, Татарстан җөмһүрияте (сабикъ (*элекке*) Казан вилайәте. – *Р.С.*) ашлык уңмау ягыннан Самар шикелле вилайәтләр *(губерналар)* белән беррәттән тора. Ләкин монда һәркемнең күзенә аермачык бәрелеп тора торган икенче бер нәрсә бар, ул да булса Татарстан җөмһүриятенең төп халкы булган татарлар шул ук Татарстанда тереклек итә торган башка халыкларга караганда ныграк ачыгалар. Без кая гына бармыйк, татарларның ачлыктан азап чиккәннәрен, балалар йортларының ач татар балалары белән тулып калганлыгын, җөмһүриятебездәге шәһәр урамнарында татарларның ачлыктан аунап ятканнарын, ниһаять татар авылларындагы йорт-җирләрнең ябылып, тәмам сүнгәнлекләрен күрәбез. Бу 1921 елны татарларның үзләре белән бергә яшәүче халыкларга караганда ныграк ачыгулары, шөбһәсез, татарларның үзләренә генә махсус булган иҗтимагый һәм икътисади

сәбәпләрдән килә. Әгәр дә без халкыбызның тарихын тикшереп карасак, татарларның иске-искедән бирле зур бер кысынкылык астында яшәп килгәнлекләрен күрәбез. Иван Грозный тарафыннан Казан алыну белән, татарлар үзләренең өсләрендә инде кысынкылыкның башланганлыгын сизделәр. Идел, Кама буйларындагы әлегә кадәр биләп килгән мөнбит *(уңдырышлы)* җирләрен татарлар урысларның тәзаййыкы *(кысуы)* астында ташлап китәргә мәҗбүр булдылар. Җүнсез һәм уңайсыз җир кайда бар – татарлар шунда утыртылды. Билгеле, бу хәл үзе генә дә татарларның иктисади яктан начарлануларына сәбәп булды" [6: 18-19]. Алга таба автор, милли тарихка күз ташлап, бу социаль фаҗиганең сәбәбен патша самодержависенең татарларга нисбәтле алып барылган милли колониаль сәясәте белән бәйли, аның тискәре нәтиҗәләре һәм бу хәлдән чыгу юллары хакында гамьнәре белән уртаклаша. Р.Сабиров карашынча, башыннан аягына кадәр христиан дине рухы белән сугарылган Русия хөкүмәте, урыс поплары белән кулга-кул тотынып, Казанны алуга татарларны чукындыру, аларны урыслаштыру сәясәтенә кереште. Бу юлда татар халкына әллә никадәр үзенең җәбер-золымын салды. Шушы яман сәясәтнең яман нәтиҗәсе буларак, бичара татарлар үз кабыкларына яшеренергә, урысның начар яклары белән бергә, барлык яхшы якларына да кырын күз белән карарга, алардан файдалы һичбер яңа нәрсә алмаска мәҗбүр булдылар. Үз диннәрен, үз гореф-гадәтләрен саклап калырга тырыша торгач, татарлар урыслардагы иген игү, көн күрү эшләрендәге төрле файдалы яңалыкларга да дошманлык күзе белән карый башладылар. Еллар, гасырлар буенча татарлар, урыс ашы дип, кәбестә, кыяр шикелле яшелчәләр җитештермәде. Шул ук сәбәп аркасында бакчачылык белән шөгыльләнмәде. <…> Әгәр дә орлыклы ашлыкларның уңышы бик үк ышанычлы булып җитмәсә, ашлык уңмау куркынычыннан бары тик иген игү эшендә яңа ысулга – игенне күп басу белән игүгә күчү һәм чәчү әйләнешенә сәнәгать өчен кирәкле үсемлекләр кертү генә коткара алачак. Бу яктан караганда, татар крестьяннарының хуҗалыклары бик әкрен үзгәрә. Халыкның ашамлык запасларын күп арттыра торган һәм аларга икмәктән башка да яшәргә мөмкинлек бирә торган бәрәңге утырту татарлар арасында яхшы ук күп таралган. Ләкин коры бәрәңгегә генә ышанып торырга туры килми. Бүгенгә кадәр татарларның күбесе игенне Нух заманынан калган ысул белән игәләр. Шуңа күрә ачлык булган елларда аларның күбрәк азап чигүләре гаҗәп түгел [6: 18-19].

Журнал, «Безнең юл» исеме белән 1930 елның апрелендә соңгы тапкыр чыгып, «Яңалиф» (Татарстан мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасы органы. – *Р.Ю.*) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат язучылар ассоциясе органы. – *Р.Ю.*) басмаларына бүленә, әмма алар икесе дә 1932 елның азагында нәшер ителүдән туктый. «Безнең юл» беренче санынннан – гарәп, 1930 елдан – латинда, ә «Яңалиф» белән «Атака» исә баштан ук латин графикасында чыга.

1933 ел башында ул «Совет әдәбияты» һәм 1965 елның 6 нчы санынннан «Казан утлары» исеме белән басыла башлый. Билгеле, чорның каршылыклы сәяси-иҗтимагый мохите журналга йогынты ясый. Үзенең традицияләрен сакларга тырышса да, ул, идеология, партия күрсәтмәләре тәэсирендә булып, төп мәсьәләләрдә хөкүмәт карарларын тормышка ашыру юнәлешендә эшчәнлек алып бара. Татар теленең алфавитын үзгәртү шундыйларның берсе булып тора. 1929 елда, җитди бәхәсләр, каршылыклар булуга карамастан, гарәп графикасы латиницага, ә ул үз нәүбәтендә 1930-1940 елларда кириллица белән алыштырыла. Бу мәсьәләләргә журнал позициясен һәм аның нинди шартларда эшләвен ачык күзаллау өчен, 1939 елның 5 нче саны соңгы битендәге «Редакциядән» дигән игъланга игътибар итик: « "Кызыл Татарстан" газетасы шушы елның 21 июлендә чыккан 165 (5666) нче номерында, "Яңа алфавитны үзләштерү эшен большевикларча оештырыйк" исемле баш мәкаләсендә, "Совет әдәбияты" журналының бу тармакта эшсезлек күрсәтүенә карата түбәндәге сүзләрне әйтә: "Республика күләмендә чыга торган журналлар арасыннан "Совет әдәбияты" журналы совет язучыларын үз тирәсенә тупларга чыгарылган. Бу журнал, әлеге мөһим эшнең үзәгендә торырга тиеш булса да, хәзергә чаклы моны эшләп күрсәткәне юк. Киресенчә, "Совет әдәбияты" журналы (редакторы иптәш Т.Имаметдинов. – *ред.*) гаять зур культура факторы булган эштән бөтенләй читтә яши. Бу яңалык беренче күтәрелгән чакларда журнал тирәсендә язучыларның фикерләрен туплау буенча бер нәрсә дә эшләмәде. Хәзер дә исә бернинди дә эш алып бармый…» [7: 96].

Алга таба шушы кимчелекләрне төзәтү юллары бәян ителә. «Совет әдәбияты» журналы

редакциясе, «Кызыл Татарстан» газетасының бу күрсәтмәләрен урынлы санап, басманың август, сентябрь номерлары яңа алфавитта бирелә башлаячагын һәм, «Камил Якуб» фабрикасында техник мөмкинлекләр булу белән, октябрь яки ноябрь номерларының тулысынча яңа алфавитта чыгарылачагын белдерә [7: 96]. Бу «игълан» үзе кириллицада, журналның 8-11 саннары ике графикада, 12 нче сан тулаем кириллицада җыелган.

Бу хәл техник кыенлыкларга гына бәйле булмыйча, билгеле бер дәрәҗәдә графика алыштыру сәясәтенә каршылык күрсәтү төсен дә ала. Моңа охшаш очрак 1920 еллар уртасында да күзәтелә. 1926 елгы «Безнең юл» ның 4 нче санында Гыйбад Алпаровның ике төрле язу графикасы турында «Латин түгел, гарәп» мәкаләсе чыга. «Электән әлифбалы, язулы халыкның, бер фаҗигале хәл булмаганда, үз ирege белән әлифба алмаштыруы, яңаны сайлап алуы булмый торган нәрсә» [8: 97], – дип яза ул. Гомумән, тел галимнәре, шул исәптән Г.Ибраһимов та, татарны урыс язуына – кириллицага күчерүнең сәясәт белән бәйле икәнлеген төшенгәннәр. Танылган классик язучы Г.Ибраһимов, журналны оештыруда турыдан-туры җитәкчелек итмәсә дә, аның эшчәнлеген җайга салуда башлап йөрүчеләрнең берсе буларак, «Безнең юл» га көчле йогынты ясый. Журналист, җәмәгать эшлеклесе Латыйф Гомәр Г.Ибраһимов турындагы истәлекләрендә бу турыда билгеләп үтә: «Билгеле булганча, бу елларда Казанда татар телендә “Безнең юл” исемле әдәби иҗтимагый-политик, нәфис журнал чыгып килә иде. Журналның төп җитәкчесе, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимов иде. Беркөнне, 1926 елның башында булса кирәк, Галимҗан ага, партия өлкә комитетының матбугат бүлегенә килеп, журналның эчтәлегеннән канәгать булмавы һәм шуның өстәвенә тиражның кечкенәлеге турында бик борчылып сөйләде:

– Анда катнашучы, үзләренең әсәрләрен бастыручы бер төркем язучылар яисә журналистлар журналы гына түгел ул, – диде. – Республика журналы ул, партия журналы! Дөресе, бөтен Советлар Союзындагы татарлар өчен чыгарыла торган бердәнбер әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал. Шуңа күрә аңа бик нык игътибар итәргә кирәк. Партия өлкә комитетының журналга игътибары җитәрлек түгел. Аның эчтәлеге, эше, торышы һәм планы белән чын-чынлап кызыксынмый. Хәтта аны тарату мәсьәләсе белән дә җитәрлек шөгыльләнми. Мәсәлән, шәһәрләрдә, шулай ук авылларда да, партия ячейкалары төрле журналлар яздыралар, ләкин шулар арасында «Безнең юл» юк [9: 185 ].

Мәкалә авторы туган хәлне уңай якка үзгәртү юллары, Г.Ибраһимовның әлеге мәсьәләне үзәккә куйган доклады хакында хәбәр итә. Аның фикеренең Г.Галиев, ФСәйфи, Ш.Фәхретдинов, С.Атнагулов, Ф.Бурнаш һәм башкалар тарафыннан яклануы, соңыннан карар кабул ителүе әйтелә [9: 185 ]. Анда журнал редколлегиясен Г.Ибраһимов, Г.Галиев, Г.Максудов составында раслау турында да искәртелә.

Г. Ибраһимовның аерым брошюра булып басылып чыккан доклады җәмәгатьчелектә киң яңгыраш ала. Язма 1927 елның 14 июнендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросында тикшерелә һәм докладта җитди ялгышлар бар дип табыла. Менә аларның кайберләре: а) милли мәдәниятнең мөстәкыйльлеген зурайтып күрсәтү, беркадәр идеаллаштыру; б) татар милли мәдәниятенең үсешендә пролетариат ролен кечерәйтү, ә милли интеллигенциянекен исә зурайту; в) фикер алышуда тыелган алымнар куллану. Олы язучының «ялгышлары» на күз салыйк әле: «Иске патшачылык заманынын татар мирзалар типлары һәркемгә мәгълүм: болар урыс хөкүмәтенең чиновниклары иделәр. Ихлас күңел белән шуңа хезмәт кылдылар, үзләренең сыйныфташлары урыс дворяннары белән бергә, бер рәвештә тәрбияләнеп, урыс мәдәнияте эчендә кайнап, татар халкыннан аерылып яшәделәр. Боларның бөтен көнкүрешләре урыс мәдәниятенә, урыс теленә баглы иде. Менә шул *бытие* (асс. – *Г.И.)* татарның бу катлавында, тик урыс мәдәниятендә генә яшәргә мөмкин, татар мәдәнияте юк, булса да – кыйммәтсез, аны күтәреп, үстерергә тырышып маташу – нәтижәсез эш, дигән *сознание (*асс. – *Г.И.)* тудырды… Урыс җәмәгатьчелеге, урыс зыялысы, урыс мәдәнияте эчендә кайнап яшәү сәбәпле, безнең хәзерге татар совет хезмәтчеләренең – чиновникларның бер өлешенә дә шул иске мирзалык чире кайтып йокты… Бездә хәзер бу яңа мирзалар аерым бер катлау булып киләләр: болар татар әдәбиятын, татар матбугатын укымыйлар, татар телендә яза белмиләр, моны үзләре өчен кимчелек дип тә карамыйлар. Үзенең бу наданлыгын ул нииндидер эчке бер “мәдәни” мактану белән әйтеп куя. Балаларын, якыннарын, әлбәттә, урыс мәктәбенә, урыс йортына, урыс

курсларына бирә…» [10: 171]. Әлеге фикерләрнең үз вакытында (һәм бүген дә! – *Р.Ю.*) актуаль яңгыравы һәм җитәкчелектә ризасызлык тудыруы җиңел аңлашыла.

«Казан утлары» журналы татар әдәби хәрәкәтен эзлекле рәвештә әйдәп бара һәм шуның белән буыннар бәйләнешен тәэмин итә. ТР Президенты Р.Н.Миңнехановның басманың 90 еллыгы уңаеннан редакция колективына котлавында әйтелгәнчә, «төп максат-миссиясе – озын-озак еллар буе имгәтелеп, бөтен дөньяга сибелеп-чәчелеп килгән әдәби-мәдәни һәм рухи мирасыбызны бергә җыю, аларны бөртекләп туплау. Җитди, тирән һәм мәгънәви эчтәлекле яңа әдәби әсәрләр тууына булышлык итү дә, яшь талантларны барлау, тәрбияләп үстерү кебек үтә мөһим эшләр дә – бердәнбер әдәби журналыбызның изге бурычыдыр» [11: 5]. Мәдәни мирасны бөртекләп җыюда һәм алдагы буыннарга тапшыруда журналның роле гаять зур. Беренче саннарыннан алып журнал битләрендә борынгы һәм урта гасыр әдәби ядкәрләренә киң урын бирелә. Бөтен төрки дөньяда танылу алган Йосыф Баласагунлы, Әхмәт Ясәви, болгар дәверенең атаклы әдибе Кол Гали, Алтын Урда дәүләте чикләрен үтеп чыккан Котб, Сәйф Сараи, Казан ханлыгы шагыйрьләре Өмми Кәмал, Колшәриф, Мөхәммәдъяр, соңрак мәйдан тоткан Мәүла Колый, Габдерәхим Утыз Имәни исемнәре һәм иҗатлары киң катлам татар укучысына журнал битләре аша барып ирешә. XIX йөзнең билгеле мәгърифәтчеләренең, XX йөз башы яңарышын тәэмин иткән әдипләрнең танылу алуы да әлеге журналдан башлана. Г.Тукай, Дәрдемәнд, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, М.Гафури, Н.Думави, Г.Камал, Ф.Әмирхан әсәрләре, аларга төрле чорларда булган мөнәсәбәт журнал битләрендә җитди бәхәсләргә китерә. Әлеге әдипләр иҗаты совет чорының идеологик йогынтысы, 1920-1930 еллар чигендәге вульгар-социологизм шаукымы, соңрак социалистик реализм таләпләре тәэсирендә төрлечә, еш кына каршылыклы бәяләнә. Әмма аның (хаталар аша булса да. – *Р.Ю.*) чын йөзен, эстетик принципларын саклап калуы югарыда аталган һәм аталмаган бик күпләрнең мирасын объектив бәяләү, әдәбият тарихындагы урынын ачык билгеләү мөмкинлеге тудыра.

Журнал 1920-1930 елларның катлаулы һәм каршылыклы сынауларын югалтулар белән, әмма үз асыл мәсләгенә тугры калып үтә. Ил күләмендә җәелгән сыйнфый көрәш мәсьәләсе журнал битләрендә дә чагыла, әдәби әсәрләрнең сыйфаты бермә-бер кими. Шулай да талантлы әдипләребез, авырлык белән булса да, укучыларда ышаныч тәрбияли, сүз сәнгатенә мәхәббәт, хакыйкатьнең җиңеп чыгачагына өмет уята. Х.Туфан, Ш.Маннур, Г.Бәширов. Г.Кутуй, М.Җәлил, Н.Баян, С.Хәким, Н.Исәнбәт һ.б. әдипләребезнең шул елларда журнал битләрендә дөнья күргән әсәрләре бүген әдәбиятыбыз түрендә урын алган. Хәсән Туфан кулга алулар аеруча көчәйгән 1937 елны «Ә йолдызлар дәшми» шигырен яза:

…Дене түгел, көне өчен генә
Яшәп илнең кайбер кибәге.
Дегетле дә, дөмгә сөйри бүген
Иң кадерле эре ирләрне…

«Совет әдәбияты» журналы авыр һәм дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларында да нәшер ителүдән туктамый. Аның битләрендә сугышка, дошманга нәфрәт, туган илне сакларга чакыру рухындагы әсәрләре белән М.Җәлил, Ф.Кәрим, Н.Арсланов, Ш.Мөдәррис, З.Нури, Ш.Мансур, Ф.Хөсни, Г.Кутуй һ.б. чыгыш ясый. Р.Гаташ билгеләп үткәнчә, шагыйрьләребезнең «шигырь-поэмалары, хәтта шул чорда немец, инглиз телләреннән тәрҗемәләре – журналыбызның асыл битләре» [12: 45]. Сугыштан соңгы елларда журнал битләре аша укучыларына Ә.Еники, Г.Бәширов, М.Әмир, С.Хәким, И.Юзеев, Х.Камал, Ш.Галиев, Ә.Баяннар эндәшә. Ә инде 1960-1970 елларда «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә башлаган журналда А.Гыйләҗев, Х.Вахит, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, С.Сөләймәнова, Р.Әхмәтҗанов, Т.Миңнуллин, алар янәшәсендә Р.Вәлиев, Зөлфәт, М.Әгъләм, А.Хәлим, К.Сибгатуллин, Р.Миңнуллин, З.Мансуров, Ф.Гыйззәтуллина, Л.Шагыйрьҗан һ.б. иҗат йөзе ачыла.

Журнал үз чорының әдәби барышына һәрдаим игътибарлы була. Т.Галиуллин язганча, «бер гасырга якын вакыт дәвамында юл башын чал тарихыбыздан алган татар шигъриятенең казанышларын кадерләп саклауга, үстерүгә йөз тотып» [13: 23] эш итә һәм иң талантлы ул-кызларын үз тирәсенә туплый. XX гасырның 80 еллар уртасында башланып киткән үзгәрешләр «Казан утлары» на да шифалы йогынты ясый. Аның битләрендә, беренчеләрдән булып, идеологик чикләүләр нәтиҗәсендә читкә кагылган әдипләрнең әсәрләре дөнья күрә, үткән мирасның аерым сәхифәләре яңадан торгызыла, әдәбият-сәнгать мәсьәләләре, аерым авторлар иҗатына кагылышы көчле бәхәсләр урын ала.

Эзлекле рәвештә милләт язмышын кайгыртып яшәгән журнал, халкыбызның асыл улларын-кызларын барлап, аларның эшчәнлеген чагылдырган күпсанлы әсәрләр бастырып чыгара. Иҗатлары сәнгати планда әдәбият казанышы буларак яңгыраш алган И.Юзеев, А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин, Р.Әхмәтҗанов, Ф.Садриев, Ә.Рәшитов, М.Галиев, З.Мансуров, Р.Зәйдулла һ.б. шәхесләргә басмада киң урын бирелә.

Журналның 1990 еллардагы саннарында милләт язмышына кагылышлы мөһим вакыйгалар һәм мәсьәләләрне, киң планда әдәби-мәдәни мирасны, тарихны яктырткан саллы язмалар урын ала. Рафаэль Мостафинның «Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре» дигән мәкаләсе – шуның бер үрнәге. Мәкалә язылуга этәргеч биргән сәбәпне автор түбәндәгечә аңлата: «Совет Татарстаны язучылары» исемле библиографик белешмәдә (Казан, 1986) атаклы язучы, галим, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесенең соңгы көннәре турында болай дип язылган: “1927 елдан башлап Г.Ибраһимов көчәеп киткән үпкә авыруы аркасында Кырымда даими яшәргә мәҗбүр була. Авыруының торган саен житди төс ала баруына карамастан, ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби һәм иҗат эшен дәвам итә. Г.Ибраһимов 1938 елнын 21 январенда Казанда больницада вафат була”. Монда китерелгән мәгълүматлар барысы да чынбарлыкка туры килә килүен. Ә тулаем алганда исә – чеп-чи ялган…» [14: 241]. Чыннан да, бөек әдибебез Кырымдагы Ялта шәһәрендә яшәп алса да, 1937 елның 29 августында кулга алына. Тикшерүчеләрдән алынган белешмәдә мондый юллар бар: “В ходе следствия Ибрагимову Г.Г. было предъявлено обвинение в том, что он в 1920 году примкнул к контрреволюционной националистической группе так называемых “левых” в татарской партийной организации, а в 1925 году с определенной частью этой группы вошел в контрреволюционную националистическую организацию, в которой играл роль одного из руководителей, проводил практическую контрреволюционную работу на культурно-идеологическом фронте”…» [14: 242]...

«Шәхес культы» хөкем сөргән шомлы еллардагы хәл-торыш Р.Мостафин язмасында түбәндәгечә тасвирлана: «Утызынчы елларда “органнарда” эшләгән, хәзер пенсиядә яшәүче берәү (фамилиясен атарга рөхсәт итмәде. – *Р.М.)* моны болай аңлатты. 1935-1936 елларда “троцкийчы-зиновьевчы-бухаринчы блок” “фаш ителгәч”, Татарстанның НКВД органнары – әллә үз теләкләре белән, әллә өстән килгән күрсәтмә буенча (соңгысы дөреслеккә якынрак булса кирәк. – *Р.М.)* бездә дә әлеге “оешманың” тармакларын эзлиләр. Төгәлрәк әйткәндә, булмаганны булды, юкны бар дип күрсәтергә ниятлиләр. Мәскәүдәге зур дәүләт эшлеклеләренә тиң булырлык, республика күләмендә шулар дәрәҗәсендә тора алырлык иң зур, иң күренекле шәхесләрдән оешма “төзиләр”. Алар арасында атаклы галимнәр, популяр язучылар, халык ихтирамын казанган сәнгать эшлеклеләре дә була… “Оешмага” җитди идеолог да кирәк була» [14: 242]. Бу вазифаны Ялтада, берни белмичә, үлем белән тарткалашып яткан Г.Ибраһимов өстенә «йөклиләр». «“Юк, мин халык дошманы түгел. Беркайчан да хаин булмадым. Үлгәндә дә большевик булып үләм”– камерадашы Габделхак Батталовка әнә шулай ди Г.Ибраһимов» [14: 242].

Бөек әдипнең большевиклар партиясенә бу кадәр тугрылыгы билгеле бер дәрәҗәдә гаҗәпләнү дә уята. Моны бары шул чорга бәйле генә аңлап һәм аңлатып була. Әлеге мәсьәләгә үз вакытында танылган артист Габдулла Шамуков игътибар итә. «Казан утлары» журналы 1992 елның 3 нче санында аның КПСС Үзәк Комитетына, СССР мәгариф министры М.А.Прокофьевка һәм РСФСР мәгариф министры А.И.Даниловка язган хатын бастыра. 1969 елның декабрендә язылган хатта татар мәгарифенең һәм татар теленең авыр хәле бәян ителә: «Гаҗәп, ни өчендер “милләтчелек” тамгасы аз санлы халык вәкилләренә генә сугыла, ә партиянең X съездында каралган төп мәсьәлә онытыла. “Съезд үзенең төп һөҗүмен иң куркыныч күренешкә – “бөек урыс” шовинизмына каршы юнәлтә” дигән сүзләр истән чыга» [15: 481].

1980 еллар ахыры – 1990 елларда «Казан утлары» журналында халкыбызның ерактагы һәм якындагы үткәненә, олы шәхесләренең эшгамәлләренә бәйле үткен сәяси-тарихи язмалар аеруча арта. Партиянең идеологик басымыннан котылу халык тарихы турында объектив һәм тулы итеп язу мөмкинлеге бирә. Б.Солтанбәковның «Гаделсезлек тантанасы» [16], Ф.Баһаветдиновның «Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре» [17], Ф. Баһаветдинов һәм А.Әхмәдуллинның «Фәтхи Бурнашның соңгы еллары» [18], И. Сәлаховның «Кара көннәр»е [19] кебек мәкаләләр – шуның ачык мисалы.

Репрессияләр чорының бөтен фаҗигасе Шамил Әхмәтовның «Мин хәзер керермен, көтегез» язмасында тулы чагыла: «Кави Нәҗми 2 июньдә, Галимҗан Ибраһимов 29 августта, Галимҗан Мөхәммәтшин белән Ибраһим Сәлахов сентябрь аенда кулга алыналар, декабрьдә Мирсәй Әмиргә чират җитә. Кави Нәҗмидән соң Татарстан язучылар берлегенә җитәкче итеп Ләбиб Гыйльмине билгелиләр. Ул искиткеч активлык күрсәтә, «халык дошманнарын» фаш итү җыелышлары үткәрә, ялкынлы нотыклар сөйли, язучыларны үз араларындагы «дошманнарны» күрмәүләре, гамьсез булулары өчен гаепли. Шундый җыелышларның берсендә швейцар кереп, Ләбибне чакыра. Ләбиб Гыйльми язучыларга:

– Иптәшләр, мин тиз генә чыгып керәм, сез фикер алыша торыгыз, – дип чыгып китә. Язучылар сүзсез генә, шомлы уйларга чумып, Ләбибне көтәләр. Шактый озак утырганнан соң, иң өлкән язучы Шәриф Камал

– Озаклады… Берәр хәл булмадымы икән? Берәрегез чыгып керегез әле, – дигәч, кемдер швейцар янына барып килә. Хәрби киемле ике кеше Ләбиб Гыйльмине … кара машинага утыртып алып киткәннәр икән. (…) Бу хәл 1937 елның 21 сентябрендә була» [20: 227].

«Казан утлары» журналы даими рәвештә татарның киләчәге өчен җан атып, халыкның бүгенге һәм иртәгесе көнен яхшырту максатына хезмәт итә. Ләкин, киләчәк юлың туры булсын өчен, үткәнгә каерылып карау кирәк. Танылган галим Т.Галиуллинның бер мәкаләсе исемендәгечә – «Тарихыңны онытсаң – юк киләчәгең…». Бу елларда Т.Әйди, М.Госманов, Ә.Кәримуллин, И.Таһиров, Т.Миңнуллин һ.б. ларның язмалары журналның иҗтимагый йөзен билгели.

2006 елның февралендә, Россиядәге һәм элекке СССР дагы бөтен әдәби журналлар арасында беренчеләрдән булып «Казан утлары» ның меңенче саны чыга. Ел азагында журналда басылган иң яхшы язмалардан тупланган «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китап дөнья күрә. Әлеге вакыйгалар һәм 2012 елда Татарстан җитәкчелеге катнашында журналның 90 еллыгын тантаналы билгеләп үтү киң җәмәгатьчелектә зур игътибар һәм кызыксыну уята. «Сүнмәс утлар балкышы» басмасын әдәбият галиме Х.Миңнегулов «Чын мәгънәсендә бер хәзинә бу… Журналның гына түгел, ә гомумән татар рухи тормышының, милли яшәешенең бер белешмәсе, чыганагы, энциклопедиясе, хрестоматиясе кебек тә ул» [21], ә язучы Адлер Тимергалин «үзе бер китапханәгә бәрабәр «Сүнмәс утлар балкышы». Мин бу утларның саллы җылысын тезләрем белән дә, күңелем белән дә тоям. Әгәр дә мәгәр бер мәлне мине адәм заты яшәми торган утрауга озатасы булып, үзем белән ун китап алырга рөхсәт итсәләр, шуларның берсе, һичшиксез, «Сүнмәс утлар балкышы» булыр иде. Алай-болай ерак йолдызларга сәяхәткә чыгып китсәм дә, үзем белән алыр идем мин аны» [22: 116], – дип билгелиләр.

«Казан утлары» бүген дә татар әдәби-мәдәни хәрәкәтенең үзәгендә тора, халыкның рухи-мәдәни ихтыяҗларына җавап бирә, сүз сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре белән таныштыруын уңышлы дәвам итә, Х.Миңнегулов язганча, «үзенең төп мәсләгенә, кыйбласына тугры» калып, «милли тормышыбызның мәркәзи учагы булып» тора [23: 22]. Буыннар алмаша, журналга яңа яшь авторлар килә. Әмма ул галиҗанәп сүзгә булган игътибарны киметми, үзенең тирән мәгънәле, яшәешнең бөтен төрлелеген чагылдыруга йөз тоткан яңадан-яңа әдәби әсәрләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, үткен публицистик язмалары, иҗтимагый тормышыбызны чагылдырган очерклары белән киң катлам укучыларын сөендереп килә.

**Әдәбият**


1. *Фәйзуллин Р.* Без булганбыз, бар һәм булачакбыз! // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният. Казан, 2012. Б. 6-8.
2. *Миңнегулов Х.Й.* «Казан утлары» һәм татар халкының әдәби-мәдәни мирасы // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният. Казан, 2012. Б.11-13.
3. «Безнең юл» идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә мөрәҗәгать // Казан утлары. 2006. №2. Б. 13.
4. *Мансуров Г.* «Безнең юл» турында // Казан утлары. 2006. №2. Б. 15.
5. *Гали М.* Журналыбыз турында // Казан утлары. 2006. № 2. Б. 20.
6. *Сабиров Р.* Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык // Казан утлары. 2006. №2. Б. 18-20.
7. Редакциядән // Совет әдәбияты. 1939. №5. Б. 96
8. *Алпаров Г.* Латин түгел гарәп // Безнең юл. 1926. № 4. Б. 96-99.
9. *Гомәр Л.* Әдип һәм көрәшче // Галимҗан Ибраһимов турындагы истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 183-196.
10. *Ибраһимов Г.* Милли мәдәният нинди юл белән барачак? // Казан утлары. 1992. №3. Б. 157-176.
11. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның «Казан утлары»

журналының 90 еллыгы уңаеннан редакция коллективына котлавы // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният. Казан, 2012. Б. 5.
12. *Гаташ Р.* «Казан утлары» журналында шигъри буыннар бәйләнеше // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният. Казан, 2012. Б. 44-46.
13. *Галиуллин Т.* Күңел хәзинәләре уртаклыгы («Казан утлары» һәм татар шигыре) // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният. Казан, 2012. Б. 23-28.
14. *Мостафин Р.* Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре // Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: ИДЕЛ-ПРЕСС, 2006. Б. 241-245.
15. *Шамуков Г.* Язучы архивыннан // Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: ИДЕЛ-ПРЕСС, 2006. Б. 241-245.
16. *Солтанбәков Б.* Гаделсезлек тантанасы // Казан утлары. 1993. №2. Б. 128-134.
17. *Баһаветдинов Ф.* Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре // Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: ИДЕЛ-ПРЕСС, 2006. Б. 218-
18. *Баһаветдинов Ф., Әхмәдуллин А.* Фәтхи Бурнашның соңгы еллары // Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: ИДЕЛ-ПРЕСС, 2006. Б. 241-245.
19. *Сәлахов И.* Кара көннәр // Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: ИДЕЛ-ПРЕСС, 2006. Б. 241-245.
20. *Әхмәтов Ш.* «Мин хәзер керермен, көтегез» // Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: ИДЕЛ-ПРЕСС, 2006. Б. 241-245.
21. *Миңнегулов Х.Й.* Мең китаптан бер китап // Мәдәни җомга. 2007, 2 март.
22. *Тимергалин А.* Сүнмәс ут янында уйда без // Казан утлары. 2008. №1. Б. 98-118.
23. *Миңнегулов Х.Й.* «Казан утлары» журналы 2011 елда // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният. Казан, 2012. Б. 14-22.

---

# ЖУРНАЛ, ОБРАЩЕННЫЙ В БУДУЩЕЕ

**Рафик Юнусович Юнусов,**
редакция журнала «Казан утлары» («Огни Казани»),
Россия, 420000, г. Казань, ул. Декабристов, д. 1,
kazanutlari@telebit.ru.

В статье систематизирован материал по истории становления и функционирования старейшего литературного татарского журнала «Казан утлары». Это один из реликтов (в прекрасном смысле) слова советской эпохи. Издание сохраняет стабильность, ежемесячную периодичность и уровень качества в эпоху, когда все переменилось до неузнаваемости. Журнал не раз менял свое название, однако оставался верен своим традициям. «Казан утлары» – современный журнал, очень удобный ориентир в мире татарской литературы. Отличительной чертой этого «толстого» журнала является тщательный отбор материала. Произведения, впервые опубликованные на страницах этого литературно-художественного журнала, в дальнейшем выходят отдельными изданиями и выдвигаются на различные литературные премии, такие как Государственная премия РТ им. Г.Тукая, РФ им. М.Горького, литературные премии Союза писателей РТ и др., и становятся финалистами и победителями. Длительное время литературная критика определяла направление, стержень журнала. Старшее поколение критиков, самоопределение которых в основном разворачивалось в поле идеологических интенций, уходит из литературной жизни. Молодые критики работают в совершенно иных социокультурных обстоятельствах, они выражают не мнение «от группы», для них более характерен эгоцентричный тип проявления самости.

В современной социокультурной ситуации журнал стремится адекватно реагировать на вызов времени. В «Казан утлары» печатаются художественные произведения, строго документальные свидетельства, посвященные ярким и драматическим судьбам и значительным историческим событиям, а также уникальные архивные находки. В журнале печатается современная проза и поэтические подборки известных мастеров литературы и тех, кому еще только предстоит обрести популярность. «Казан утлары» – трибуна для обсуждения ключевых проблем, связанных с национальной историей и культурой татарского народа. Меняется Россия, меняются авторы, сотрудники и читатели. Одно остается неизменным: журнал «Казан утлары» и сегодня остается органичной, живой частью татарской культуры.

**Ключевые слова:** история татарской журналистики, татарская литература, журнал «Казан утлары», история, рубрики, юбилей.